Исполнительный комитет
Тихоновского сельского поселения
Менделеевского муниципального
района Республики Татарстан
423655 Менделеевский район с.Тихоново ул. Шишкина д.3а

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Тихоново авыл жирлеге
башкарма комитеты
423655 Менделеевск районы Тихоново авылы Шишкин урамы 3а

тел./факс 8 (85549) 3-43-62, E-mail: Tihon.Men@tatar.ru

# КАРАРЫ

2022 елның 5 декабреннән №5

"Булгарнефть" АЖ НПС проекты
линия объектларына территорияне
планлаштыру проекты һәм аның составындагы
территорияне ызанлау проекты буенча
гавами тыңлаулар үткәрү турында

Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 3 декабрендәге 681 номерлы карары нигезендә, шулай ук «Геомониторинг» ҖЧҖ 2022 елның 21 декабрендәге 4-067 номерлы хаты нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы, Тихоново авыл җирлеге Уставы, гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 9 гыйнварында 16 сәгатьтә Менделеевск районы, Тихоново авылы, Коммунистлар урамы, 27В йорты адресы буенча урнашкан Тихоново авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл җирлеге чикләрендә урнашкан "Булгарнефть АҖнең Мамадыш нефть һәм газ чыгару цехының нефть санын һәм параметрларын үлчәү системасы белән нефть суыртү станциясе" проектының линия объектларына территорияне планлаштыру проекты һәм аның составындагы территорияне ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру комиссиясен түбәндәге составта төзергә:

Карманов А.М. - Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге башлыгы, комиссия рәисе;

Филатов А.А. - Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл җирлеге рәисе урынбасары (5 нче округ);

Самматов Р.А. - Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге депутаты (4 нче округ).

3. 2022 елның 6 декабреннән 2023 елның 9 гыйнварена кадәрге чорда Менделеевск районы, Тихоново авылы, Коммунистлар урамы, 27В йорты адресы буенча урнашкан Тихоново авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл җирлеге чикләрендә урнашкан "Булгарнефть АҖнең Мамадыш нефть һәм газ чыгару цехының нефть санын һәм параметрларын үлчәү системасы белән нефть суыртү станциясе" проектының линия объектларына территорияне планлаштыру проекты һәм аның составындагы территорияне ызанлау проекты материаллары экспозициясен оештырырга.

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә (җибәрелә): 423655, Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Тихоново авылы, Шишкин ур., 3А йорт (Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге башлыгы исеменә).

5. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының «Интернет» челтәрендә рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatar.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru «Тихоново авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Тихоново авыл җирлеге башлыгы А.М. Карманов